**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАТЮШИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 д.Матюшино,
ул. Березовая, д.25
тел, факс: 267-01-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАТЮШИНО БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422624 Матюшино авылы,
Каенлык урамы, 25 нчы йорт,
тел, факс: 267-01-44

**№ 2** **2019 елның 12 апреленнән**

КАРАР

**Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

2010 елның 27 июленнән № 210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән №880 “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында”гы карарына, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 13 ноябреннән №2027 “Лаеш муниципаль районымуниципаль хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы карарына ярашлы төстә**карар бирәм**:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын (Кушымта) расларга.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында Интернетның мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Матюшино авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 16 августыннан №12 “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы карарын көчен югалткан дип табарга.

4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Матюшино авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

**Җитәкче** **Н.И.Миңнуллина**